**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Кәркәүч авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**13 ноябрь 2021 ел** **№ 1**

**«Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Ташлы-Елга авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2021 елның 23 ноябренә 9 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Ташлы-Елга авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Ташлы-Елга авылы, Татарстан, 3а нче йорт адресы буенча урнашкан фельдшер-акушерлык бинасында үткәрергә.

2. 2021 елның 23 ноябренә 10 сәгать 00 минутка һәм 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Ташлы-Елга авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче, өченче этабларын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Ташлы-Елга авылы, Татарстан урамы, 60 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

3. 2021 елның 23 ноябренә 15 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Ташлы-Елга авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Ташлы-Елга авылы, Татарстан урамы, 51 нче йорт адресы буенча урнашкан мәчет бинасында үткәрергә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, 18 яшькә кадәрге 4 һәм аннан да күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләр, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Ташлы-Елга авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Ташлы-Елга авылының Татарстан урамы буенча юлга вак таш җәю, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Ташлы-Елга авылындагы юлларны кардан чистарту; түләү килешенү буенча;
- Тирәннән су суыртү насосы алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

6. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Кәркәүч авылы Башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Кәркәүч авыл җирлеге башлыгы М.Ф.Зәйнетдинов